РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ КОРСАБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422051, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Корсабаш, ул. Школьная, д. 28
тел. (84362) 2-27-49

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУРСАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422051, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Курсабаш авылы, Школьная урамы, 28 йорт
тел. (84362) 2-27-49

e-mail: korsab.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
23.10.2024

КАРАР
№20

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Курсабаш авыл җирлеге Советының
2021 елның 29 сентябрендәге 21 номерлы
карары белән расланган Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге
чикләрендә муниципаль җир контроле турында
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 08.08.2024 ел, №289-ФЗ Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районының Курсабаш авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне раслау хакында» 29.09.2021 ел, №21 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 5.11.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.11.3. Планнан тыш күчмә тикшерү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»31.07.2020 №248 - ФЗ Федераль законның 1 өлешендәге 3-6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.»;

1.2. 5.12.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12.4. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге нигезләмәнең 5.1 пунктының 2 пунктчасында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел".

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru.

Курсабаш авыл җирлеге башлыгы А. Р. Гыймадиев